ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӨРЕШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БӨРЕШЛЕ АВЫЛЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР

30.11. 2023 ел №1

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45 -РТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 30 ноябрендәге Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында тавыш бирү нәтиҗәләре турында» гражданнар җыены киңәшмәсенең, исәп комиссиясе беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылы гражданнар җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, I һәм II төркем инвалидлардан, балигъ булмаган күпбалалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы студентларыннан, 18 яшькә кадәрге баланы тәрбияләүче ялгыз аналардан, 80 һәм өлкәнрәк яшькә җиткән затлардан, Россия Федерациясе Хәрби көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә 2024 елда үзара салым кертү белән сез килешәсезме:

1) Бөрешле авылының Яшьләр урамында юлларга вак таш җәю;

2) Су алу өчен электр насослы скважина агрегаты сатып алу;

3) Янгын сүндерү җиңе сатып алу;

4) Бөрешле авылында юлларны кардан чистарту;

5) Бөрешле авылы территориясен чабу?» дигән сорауга карар кабул ителгән дип санарга.

3. Гражданнар җыенының карарын Бөрешле авылының мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk. tatarstan.ru «Бөрешле авыл җирлеге» бүлегендә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Бөрешле авыл җирлеге башлыгы Л.А.Смирнова